**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
«Мальбагушского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района

ул. Нефтяников дом 30 , с. Мальбагуш Азнакаевского муниципального района 423308,

тел 37-7-91, факс 37-7-91

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
«Мәлбагыш авыл җирлеге»
башкарма комитеты

Азнакай муниципаль районы, Мәлбагыш авылы, Нефтчеләр урамы , 30 йорт

тел 37-7-91, факс 37-7-91

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«11» февраль 2020 ел №9

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 26 декабрендәге 50 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү муниципаль программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә, 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның 2019 елның 23 декабрендә «Татарстан Республикасы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү» мәсьәләсе буенча видеоконференция режимында республика киңәшмәсе нәтиҗәләре буенча күрсәтмәләре исемлегенең 4.7 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 26 декабрендәге 50 номерлы «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү буенча муниципаль программа турында» карары белән расланган, 2020-2022

елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү муниципаль программасына «Чаралар исемлеген» түбәндәге эчтәлекле 4 бүлек белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

| 4. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4.1 | Озак вакытка исәпләнгән нигездә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына өченче затлар хокукларыннан азат ителгән муниципаль мөлкәтне бирү | 2020-2022 еллар | Финанслау таләп ителми | - | - | - | - | Авыл җирлеге башкарма комитеты |

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык: И.Ә.Әхтәмова